**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2015 ел, 6 апрель | № 221

г. Казань

2015 елда Татарстан Республикасы хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә үткәрелә торган өстәмә чаралар кысаларында социаль проект-ларны тормышка ашыру өчен яшьләргә грант ярдәме күрсәтү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елга Татарстан Республикасы хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендәге өстәмә чараларны тормышка ашыру» дәүләт программасын раслау турында» 2015 ел, 18 март, 162 нче карарын тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2015 елда Татарстан Республикасы хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә үткәрелә торган өстәмә чаралар кысаларында социаль проектларны тормышка ашыру өчен яшьләргә грант ярдәме күрсәтү тәртибен (алга таба - Тәртип) расларга.

2. Тәртипне куллану буенча аңлатмалар бирү Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры | И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\221.doc

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 6 апрель, 221 нче
карары белән расланды

2015 елда Татарстан Республикасы хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә үткәрелә торган өстәмә чаралар кысаларында социаль проектларны тормышка ашыру өчен яшьләргә грант ярдәме күрсәтү

# ТӘРТИБЕ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1. 2015 елда Татарстан Республикасы хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә үткәрелә торган өстәмә чаралар кысаларында социаль проектларны тормышка ашыру өчен яшьләргә грант ярдәме күрсәтү тәртибе (алга таба – Тәртип) «Россия Федерациясендә халыкның эш белән тәэмин ителеше турында» Россия Федерациясе Законын, «Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыру турында» Татарстан Республикасы Законын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елга Татарстан Республикасы хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендәге өстәмә чараларны тормышка ашыру» дәүләт программасын раслау турында» 2015 ел, 18 март, 162 нче карары белән расланган 2015 елга Татарстан Республикасы хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендәге өстәмә чараларны тормышка ашыру» дәүләт программасын (алга таба – Дәүләт программасы) тормышка ашыру максатларында, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендәге өстәмә чараларны тормышка ашыруга 2015 елда федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр бирү һәм бүлү турында» 2015 ел, 22 гыйнвар, 35 нче карары нигезендә эшләнде.

Тәртип законда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән һәм үз эшчәнлекләрен Татарстан Республикасы территориясендә конкурс буенча сайлау алу үткәрелү турында иълан ителгән көнгә кадәр кимендә бер ел эчендә гамәлгә ашыра торган, гамәлгә куючылары (катнашучылары) 22 яшьтән 30 яшькә кадәрге яшьләр булган теләсә кайсы оештыру-хокук рәвешендәге һәм милек рәвешендәге юридик затларга (алга таба – оешма) (бу пунктның өченче абзацында күрсәтелгән оешмалардан тыш) бу Тәртипнең 11 нче пункты таләпләренә җавап бирә торган социаль проектларны тормышка ашыруга конкурс нигезендә грантлар бирү механизмын билгели.

Социаль проектны тормышка ашыруга грант (алга таба – грант) сәяси партияләр һәм хәрәкәтләр, һөнәр берлекләре рәвешендәге коммерциягә карамаган оешмаларга, шулай ук бетерелү, үзгәртеп оештырылу, бөлгенлеккә төшү процедуралары гамәлгә ашырылган һәм/яки эшчәнлекләре законнарда билгеләнгән тәртиптә туктатылып торган һәм/яки Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына мәҗбүри түләүләр буенча кредиторлык бурычлары булган оешмаларга бирелми.

2. Грант оешмага федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр исәбеннән һәм Дәүләт программасын тормышка ашыру кысаларында күздә тотылган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 300 мең сум күләмендә бирелә.

Грант бирүнең максаты – Татарстан Республикасы хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендәге өстәмә чараларны тормышка ашыру кысаларында яшьләргә ярдәм күрсәтү.

3. Татарстан Республикасы хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендәге өстәмә чараларны тормышка ашыру кысаларында социаль проектны гамәлгә ашыру өчен яшьләргә грант ярдәме күрсәтү буенча конкурс (алга таба – конкурс) үткәрүне оештыру, шулай ук җиңүче оешмалар белән грант бирү турында шартнамә төзү Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – вәкаләтле орган) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

## II. Конкурс үткәрүне оештыру

4. Вәкаләтле орган бу Тәртип кысаларында:

Татарстан Республикасы хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә үткәрелә торган өстәмә чараларны тормышка ашыру кысаларында социаль проектларны тормышка ашыру өчен яшьләргә грант ярдәме күрсәтү буенча конкурс комиссиясе (алга таба – конкурс комиссиясе) төзи һәм аның составын раслый;

конкурсны игълан итә;

конкурста катнашуга гаризалар әзерләү мәсьәләләре буенча консультацияләр оештыра;

конкурста катнашуга гаризалар (алга таба – гаризалар) кабул итүне һәм теркәүне оештыра;

конкурста катнашуга кертелгән оешмалар исемлеген раслый;

конкурста катнашуга тапшырылган гаризаларның сакланышын тәэмин итә;

конкурс комиссиясе эшчәнлеген оештыру-техник яктан тәэмин итүне гамәлгә ашыра;

оешмалар –- конкурста җиңүчеләр белән грант бирү турында шартнамә төзи;

конкурс комиссиясе карары нигезендә оешмалар – конкурста җиңүчеләр исемлеген раслый;

бирелгән грантларның максатчан файдаланылуын тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыра.

5. Оешмаларны конкурс буенча сайлау алуны һәм оешмалар – конкурста җиңүчеләр исемлеген билгеләүне конкурс комиссиясе гамәлгә ашыра.

## III. Конкурс комиссиясе

6. Конкурс комиссиясе:

конкурста катнашу өчен оешмалардан кергән гаризаларны карауны һәм материалларны бәяләүне гамәлгә ашыра;

оешмалар - конкурста җиңүчеләр исемлеген билгели.

7. Конкурс комиссиясе утырышы, әгәр анда конкурс комиссиясе әгъзаларының билгеләнгән санынннан яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы була.

8. Конкурс комиссиясе карарлары ачык тавыш бирү юлы белән аның утырышында катнашучы конкурс комиссиясе әгъзалары тавышларының гади күпчелеге белән кабул ителә.

Конкурс комиссиясе әгъзаларының тавышлары тигез булса, конкурс комиссиясе рәисе хәлиткеч тавыш хокукына ия була.

9. Конкурс комиссиясе карарлары аның утырышында катнашкан конкурс комиссиясе әгъзалары кул куя һәм конкурс комиссиясе утырышы үткәрелгән вакыттан календарь көннәрдә исәпләнә торган биш көн эчендә конкурс комиссиясе рәисе тарафыннан раслана торган конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә. Конкурс комиссиясе әгъзаларының аерым фикере булса, бу фикерләр шулай ук конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсенә кертелә.

Конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсе беркетмә расланган көннән өч эш көненнән дә соңга калмыйча вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәркем файдалана алырлык итеп урнаштырылырга тиеш.

10. Әгәр конкурс комиссиясе әгъзасы конкурс йомгаклары белән шәхсән (турыдан-туры яки читләтеп) кызыксынуын белдерсә яки конкурс комиссиясе әгъзасының конкурс комиссиясе эшендә катнашуына йогынты ясый ала торган башка хәлләр булса, ул бу хакта конкурс комиссиясенә язма рәвештә хәбәр итәргә тиеш.

Конкурс комиссиясе әгъзасының шәхсән кызыксынуы булу турында мәгълүмат конкурс комиссиясенә өченче затлар тарафыннан җибәрелергә мөмкин.

Конкурс комиссиясе әгъзасының шәхсән кызыксынуы төшенчәсен конкурс комиссиясе әгъзасы өчен турыдан-туры, аның якын туганнары, шулай ук конкурс комиссиясе әгъзасы финанс йөкләмәләре яки башка йөкләмәләр белән бәйле булган гражданнар яки оешмалар өчен аның акчалата йә натурлата керемнәр, матди файда рәвешендә керемнәр алу мөмкинлеге дип аңларга кирәк.

Конкурс комиссиясе әгъзасының конкурс комиссиясе эшендә катнашуына йогынты ясарга мөмкин булган хәлләргә түбәндәгеләр керә:

соңгы 12 ай эчендә конкурс комиссиясе әгъзасының яки аның якын туганнарының конкурста катнашучы оешма эшчәнлегендә гамәлгә куючы, күмәк орган әгъзасы, бер үзе хәл итә торган башкарма орган яки хезмәткәр буларак катнашуы;

соңгы 12 ай эчендә конкурс комиссиясе әгъзасының яки аның якын туганнарының конкурста катнашучы булган оешманың гамәлгә куючысы, катнашучысы, әгъзасы булган оешма эшчәнлегендә гамәлгә куючы яки бер үзе хәл итә торган башкарма орган буларак катнашуы;

соңгы 5 ел эчендә конкурс комиссиясе әгъзасының яки аның якын туганнарының конкурста катнашучы булган оешма белән шартнамәле мөнәсәбәтләрдә булуы;

соңгы 5 ел эчендә конкурс комиссиясе әгъзасының яки аның якын туганнарының конкурста катнашучы булган оешмадан акча, башка мөлкәт, матди табыш (шул исәптән түләүсез башкарылган эшләр, хезмәт күрсәтүләр рәвешендә) алуы;

соңгы 5 ел эчендә конкурс комиссиясе әгъзасының яки аның якын туганнарының конкурста катнашучы булган оешма, аның гамәлгә куючысы яки җитәкчесе белән суд бәхәсләре булу;

соңгы 12 ай эчендә конкурс комиссиясе әгъзасының конкурста катнашучы булган оешма эшендә ихтыярый зат буларак катнашуы;

конкурс комиссиясе әгъзасының конкурста катнашучы булган оешмага конкурста катнашуга гариза әзерләүдә булышлык күрсәтүе (гариза әзерләү буенча сорауларга җаваплар бирү юлы белән түләүсез нигездә консультация бирү очракларыннан тыш).

Конкурс комиссиясе, әгәр дә аңа конкурс комиссиясе әгъзасының конкурс комиссиясе эшендә катнашуына йогынты ясый ала торган хәлләр булу турында билгеле булса, конкурс комиссиясе әгъзасыннан шәхсән кызыксынуы булу турында язма гариза яки өченче заттан тиешле мөрәҗәгать алган вакыттан календарь көннәрдә исәпләнә торган ун көн эчендә аларны карарга һәм түбәндәге карарларның берсен кабул итәргә тиеш:

1) конкурс комиссиясе әгъзасының конкурс комиссиясе эшендә катнашуын туктатып торырга;

2) конкурс комиссиясе әгъзасын шәхсән кызыксындыра торган конкурста катнашу турындагы гаризаларны яки конкурс комиссиясе әгъзасының конкурс комиссиясе эшендә катнашуына йогынты ясый ала торган башка хәлләрне конкурс комиссиясе әгъзасын тиешле гаризаларны тикшерүдә катнаштырмыйча яки конкурс комиссиясе утырышында конкурс комиссиясе әгъзасы булмаганда карарга;

3) конкурс комиссиясе әгъзасының теге яки бу конкурс нәтиҗәләре белән шәхсән кызыксынуы булмау турында белдерергә.

Конкурс комиссиясе әгъзасының конкурс йомгаклары белән шәхсән кызыксынуы яки конкурс комиссиясе әгъзасының конкурс комиссиясе эшендә катнашуына йогынты ясый ала торган башка хәлләр булу турында мәгълүмат, шулай ук мондый мәгълүматны карау нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе кабул иткән карарлар конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсендә күрсәтелә.

## IV. Социаль проектларны тормышка ашыруның өстенлекле юнәлешләре

11. Оешмаларның конкурска тәкъдим ителгән социаль проектлары түбәндәгеләргә йөз тотарга тиеш:

конкурска тәкъдим ителә торган проект тормышка ашырылган чорга 22 яшьтән 30 яшькә кадәрге яшьләр, шул исәптән белем бирү оешмаларын тәмамлап чыгучылар өчен бу эш урыннарына аларны эшкә урнаштыру шарты белән кимендә дүрт эш урыны булдыруга;

түбәндәге социаль юнәлешләр буенча бер яки берничә бурычны хәл итүгә;

социаль ятимлекне профилактикалауга, аналарга һәм балаларга булышлык күрсәтүгә;

сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар белән эшләүгә;

өлкән яшьтәге кешеләрнең тормыш сыйфатын күтәрүгә;

Бөек Ватан сугышы ветераннарына максатчан ярдәм күрсәтүгә;

инвалидларның эшкә урнашуына, адаптацияләнүенә һәм эш урыннарында беркетелүенә булышлык күрсәтүгә;

гражданнарның социаль якланмаган, аз керемле категорияләренә һәм тормыш хәле авыр булган гражданнарга законнар нигезендә түләүсез юридик ярдәм күрсәтүгә;

яшьләрнең хезмәт белән тәэмин ителүенә булышлык күрсәтүгә.

## V. Конкурсны үткәрү тәртибе

12. Конкурс үткәрү турында игълан гаризалар кабул итә башлауга кимендә 10 календарь көн кала вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

13. Конкурста катнашуга гаризалар кабул итү вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылган конкурс үткәрелү турындагы игъланда күрсәтелгән гаризалар кабул итә башлау көненнән календарь көннәрдә исәпләнә торган 20 көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Гаризалар кабул итү туктатыла торган көн булып вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылган конкурс үткәрелү турындагы игъланда күрсәтелгән гаризалар кабул итә башлау көненнән 20 нче календарь көн санала.

14. Конкурста катнашу өчен вәкаләтле органга гариза һәм вәкаләте орган раслый торган формалар буенча проектның тасвирнамәсен, шулай ук оешманы гамәлгә кую документларының оешманың вәкаләтле заты имзасы һәм мөһер белән таныкланган күчермәләрен кертергә кирәк.

15. Оешмалар үз теләкләре буенча вәкаләтле органга түбәндәге документларны кертергә хокуклы:

юридик затны дәүләт теркәвенә алу турындагы таныклыкның билгеләнгән тәртиптә таныкланган күчермәләрен;

юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан чыгармалар;

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына мәҗбүри түләүләр буенча кредиторлык бурычлары булмауны раслый торган документ.

16. Оешма бу Тәртипнең 15 нче пунктында күрсәтелгән документларны кертмәгән очракта, вәкаләтле орган әлеге документларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү тәртибендә соратып ала.

17. Бер оешма бары тик бер генә гариза бирә ала, аның составында конкурста катнашу өчен бары тик бер социаль проект кына тәкъдим ителергә мөмкин.

18. Гариза теркәлгән документлар белән бергә тегелергә, бит саннары куелырга һәм оешманың вәкаләтле заты имзасы һәм мөһер белән таныкланырга тиеш. Барлык документлар күренерлек итеп бастырылырга тиеш. Кырулар һәм төзәтүләр (мөһер белән беркетелгән һәм оешма имзасы белән таныкланган төзәтмәләрдән тыш) рөхсәт ителми.

Гариза һәм бу Тәртипнең 15 нче пунктында күрсәтелгән документлар кәгазь һәм электрон чыганакларда турыдан-туры вәкаләтле органга кертелә яки аңа почта аша җибәрелә.

19. Конкурста катнашу өчен гаризаны һәм бу Тәртипнең 15 нче пунктында күрсәтелгән документларны кабул иткәндә вәкаләтле орган аларны кергән көннәрендә конкурста катнашу турындагы гаризаларны исәпкә алу журналында терки һәм оешмага, гаризаны алу датасын һәм бирелгән теркәү санын күрсәтеп, аны алу хакында расллама кәгазе бирә.

Конкурста катнашу турында гариза һәм бу Тәртипнең 15 нче пунктында күрсәтелгән документлар вәкаләтле органга почта аша керсә, алар кергән көннәрендә конкурста катнашу турындагы гаризаларны исәпкә алу журналында теркәлә. Бу очракта гаризаны алу турында расллама кәгазе тутырылмый.

20. Конкурста катнашу өчен тапшырылган гаризаларны һәм бу Тәртипнең 15 нче пунктында күрсәтелгән документларны вәкаләтле орган конкурста катнашу турындагы гаризаларны кабул итеп бетергән көннән календарь көннәрдә исәпләнә торган ун көн эчендә бу Тәртиптә билгеләнгән таләпләргә һәм шартларга туры килү-килмәү буенча тикшерә.

Гариза биргән оешма, әгәр оешма һәм/яки оешма керткән гариза һәм документлар бу Тәртиптә билгеләнгән таләпләргә туры килмәсә, конкурста катнашуга кертелми.

21. Гаризаларга үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре турында вәкаләтле орган оешмаларга бу Тәртипнең 20 нче пунктында күрсәтелгән гаризаларны тикшерү вакыты чыккан көннән календарь көннәрдә исәпләнә торган өч көн эчендә хәбәр итә.

22. Оешмаларның конкурста катнашуга кертелгән гаризалары конкурс комиссиясе тарафыннан конкурста катнашу турындагы гаризаларны кабул итеп бетергән көннән календарь көннәрдә исәпләнә торган ун көн эчендә карала.

Конкурс комиссиясе гаризаларны бу Тәртипнең VI бүлегендә билгеләнгән һәр бәяләү критерие таләпләре нигезендә бәяли.

Конкурс комиссиясе баллар системасы буенча һәр гаризаның рейтингын билгели. Иң зур йомгаклау рейтингын җыйган гаризага беренче тәртип саны куела. Гаризаларның тәртип саннарын алга таба бүлү йомгаклау рейтингы кими бару тәртибендә гамәлгә ашырыла.

Һәр гариза баллар системасы буенча бу Тәртипнең 25 нче пунктында бәян ителгән критерийларның һәркайсы буенча конкурс комиссиясенең һәр әгъзасы тарафыннан аерым бәяләнә. Критерийларның һәрберсе 1 баллдан 10 баллга кадәр бәяләнә. Аерым критерий буенча һәр гаризаның йомгаклау баллы бу критерий буенча комиссиянең барлык әгъзаларының бөтен баллары бәяләренең уртача

арифметик суммасы буларак билгеләнә. Һәр гаризаның гомуми йомгаклау рейтингы барлык критерийлар буенча бу гаризаның йомгаклау баллары суммасы буларак билгеләнә.

Берничә гаризаның йомгаклау рейтингы бер үк төрле булган очракта, кечерәк тәртип саны башка гаризалардан алдарак кергән гаризага бирелә.

23. Грант бирелә торган оешмалар – конкурста җиңүчеләр исемлегенә гаризаларына беренче җиде сан бирелгән оешмалар (алга таба – җиңүче оешмалар исемлеге) кертелә. Калган оешмаларга грант бирелми.

Җиңүче оешмалар исемлеге конкурс комиссиясе тиешле карар кабул иткән көннән календарь көннәрдә исәпләнә торган өч көн эчендә конкурс комиссиясе карары нигезендә вәкаләтле орган тарафыннан раслана. Конкурс комиссиясе кабул иткән карар нәтиҗәләре турындагы хәбәрнамә оешмага вәкаләтле орган тиешле карарны раслаган көннән календарь көннәрдә исәпләнә торган өч көн эчендә вәкаләтле орган тарафыннан язма рәвештә җибәрелә. Җиңүче оешмалар исемлеге ул расланган көннән календарь көннәрдә исәпләнә торган биш көн эчендә вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

24. Гаризасына бердән алып җидегә кадәр тәртип саны куелган оешма вәкаләтле орган белән грант бирү турында шартнамә төзүдән баш тартса, конкурс комиссиясе календарь көннәрдә исәпләнә торган өч көн эчендә грантны гаризасына җиденче тәртип санынннан соң килүче сан куелган оешмага бирү турында карар кабул итә.

Конкурс комиссиясе кабул иткән карар нәтиҗәләре турындагы хәбәрнамәне вәкаләтле орган оешмага тиешле карарны вәкаләтле орган раслаган көннән календарь көннәрдә исәпләнә торган өч көн эчендә язма рәвештә җибәрә. Кабул ителгән карар турында мәгълүмат тиешле карар вәкаләтле орган тарафыннан расланган көннән календарь көннәрдә исәпләнә торган ун көн эчендә вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

Конкурста катнашучы конкурс комиссиясе карарына карата Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә шикаять бирергә хокуклы.

## VI. Конкурста катнашу турындагы гаризаларны бәяләү критерийлары

25. Гаризаларны бәяләү түбәндәге критерийлар буенча гамәлгә ашырыла:

социаль проектларны тормышка ашыру бу Тәртипнең 11 нче пунктында күрсәтелгән юнәлешләргә туры килү;

проект хәл итәргә йөз тоткан бурычларның актуальлеге;

оешманың проектны тормышка ашыру өчен кирәкле матди-техник базасы һәм урыннары булу;

оешманың социаль проектларны тормышка ашыру тәҗрибәсе булу;

эшләр, хезмәт күрсәтүләр кыйммәтен кертеп, проектны тормышка ашыруга бюджеттан тыш чыганаклардан керер дип көтелгән акча (шул исәптән ихтыярый затлар (волонтерлар) бушлай башкара (күрсәтә) торган эшләр) күләме,

шулай ук проектны тормышка ашыру өчен кирәкле матди-техник чаралар, мөлкәти хокуклар (бу Тәртипнең 2 нче пунктында каралган грант күләменең кимендә 30 проценты) булу;

проектны тормышка ашыру кысаларында инновацион социаль технологияләр эшләү һәм кертү;

социаль проектны тиражлау потенциалы булу;

проектны бюджеттан тыш чыганаклар исәбеннән алга таба тормышка ашыру мөмкинлеге булу;

проектны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеге күрсәткечләре булу, алар проект бурычларына туры килү;

социаль әһәмияткә ия булган проектны тормышка ашыру өчен матди-техник ресурслар бирү турындагы ниятләр хакында өченче затлар белән шартнамәләр булу.

## VII. Грантлар бирү һәм алардан файдалану тәртибе

26. Грант бирү вәкаләтле орган һәм вәкаләтле орган раслаган җиңүче оешмалар исемлегенә кергән оешма арасында төзелгән шартнамә (алга таба – шартнамә) нигезендә гамәлгә ашырыла. Шартнамә җиңүче оешмалар исемлеген вәкаләтле орган раслаган көннән календарь көннәрдә исәпләнә торган ун көн эчендә рәсмиләштерелә. Шартнамә формасы вәкаләтле орган боерыгы белән раслана.

Шартнамәдә грантның максатчан билгеләнеше һәм аның күләме, грант бирү шартлары, тәртибе, бирү вакытлары һәм грантны күчерү графигы, грантны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеге күрсәткечләре, гранттан файдалану турында хисап бирү тәртибе һәм формасы, грант акчасыннан максатчан файдаланмаган һәм/яки аны биргәндә билгеләнгән шартлар бозылганда грантны кире кайтару тәртибе, грант алучының хисап финанс елында грантның файдаланылмый калган акчасын агымдагы финанс елында кире кайтару очраклары, грант алучының грант бирү шартларын, максатларын һәм аны бирү тәртибен үтәвенә, бу Тәртип шартларын һәм төзелә торган шартнамәне үтәвенә вәкаләтле орган һәм Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы тарафыннан тикшерүләр гамәлгә ашыруга грант алучының ризалыгы турындагы шартлар күрсәтелә.

27. Күрсәтелгән максатларга каралган акча вәкаләтле орган исәбенә кергәннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә вәкаләтле орган грантны шартнамә нигезендә грант алучының хисап исәбенә күчерә.

Гранттан файдалану вакытлары бу грант бирелгән финанс елы белән чикләнә.

28. Оешма бирелгән грант исәбеннән социаль проектны тормышка ашыру өчен кирәкле чыгымнарны гамәлгә ашырырга хокуклы, шул исәптән түбәндәгеләр буенча:

хезмәт өчен түләү;

товарларга, хезмәт күрсәтүләргә, эшләргә түләү, аренда түләве;

проектны тормышка ашыру өчен кирәкле җиһазлар һәм матди-техник чаралар сатып алу;

Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле дәрәҗәдәге бюджетына салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре түләү һәм башка мәҗбүри түләүләрне кертү;

матди булмаган активлар (электрон хисаплау машиналары өчен программалар) сатып алу.

29. Бирелгән грантлар исәбеннән оешмаларга түбәндәгеләргә бәйле булган чыгымнарны гамәлгә ашыру тыела:

коммерция оешмаларына ярдәм күрсәтүгә;

социаль проектны тормышка ашыруга турыдан-туры бәйле булмаган эшчәнлекне гамәлгә ашыруга;

сәяси партияләргә һәм сайлау кампанияләренә булышлык күрсәтүгә;

митинглар, демонстрацияләр, пикетлар үткәрүгә;

фундаменталь фәнни тикшеренүләргә;

исерткеч эчемлекләр һәм тәмәке продукциясе сатып алуга;

штрафлар түләүгә.

## VIII. Грантлар бирү чыгымнарын финанслау тәртибе

30. Оешмаларга грант бирү чыгымнарын финанслау Татарстан Республикасы хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендәге өстәмә чараларны тормышка ашыру өчен күздә тотылган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы һәм Дәүләт программасы нигезендә Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан субсидияләр исәбеннән гамәлгә ашырыла.

31. Вәкаләтле орган, Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән алынган вәкаләтле органның шәхси исәбенә акча керү турындагы чыгармага таянып, акчаны билгеләнгән лимитлар нигезендә оешмалар исәпләренә күчерә.

32. Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән оешмаларга грантлар бирү чыгымнарын финанслау тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетында әлеге максатларга күздә тотылган акча күләмнәре нигезендә вәкаләтле орган тарафыннан гамәлгә ашырыла.

33. Вәкаләтле орган оешмаларга акчаны бу Тәртипнең 26 нчы пункты нигезендә күчерә.

34. Грантның агымдагы елның 31 декабре хәленә карата файдаланылмый калган акчасын оешма шартнамәдә күздә тотылган очракларда 2016 елның беренче ун эш көне эчендә вәкаләтле органга кире кайтарып бирергә тиеш.

## IX. Йомгаклау нигезләмләре

35. Вәкаләтле орган һәм Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы оешмаларга грантлар бирү өчен бүлеп бирелгән бюджет акчасын бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлүгә законнарда билгеләнгән тәртиптә тикшерү гамәлгә ашыра.

36. Оешмаларга грантлар бирү өчен бүлеп бирелгән акча түбәндәге очракларда тиешле таләпне алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган утыз көн эчендә оешма тарафыннан вәкаләтле органга кире кайтарып бирелергә тиеш:

оешманың грантны тормышка ашыруга бәйле булган чыгымнар буенча дөрес булмаган мәгълүматлар кертү фактлары ачыкланганда;

гранттан максатчан файдаланмаганда;

грант бирү турындагы шартнамәдә яки бу Тәртиптә каралган шартлар үтәлмәгәндә.

Гранттан максатчан файдаланылмаган очракта, ул максатчан файдаланылмаган суммада кире кайтарылырга тиеш.

37. Бу Тәртипнең 36 нчы пунктында күрсәтелгән нигезләр буенча бу акчаны кире кайтару вакыты бозылган очракта, бу Тәртипнең 36 нчы пунктындагы беренче абзацта билгеләнгән вакыт чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә вәкаләтле орган әлеге акчаны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә федераль бюджетка һәм Татарстан Республикасы бюджетына түләттерү чараларын күрә.

Әлеге акчаны федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты керемен үз ирекләре белән кире кайтарудан баш тартсалар, ул гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелергә тиеш.

38. Оешмаларга грантлар бирү өчен бүлеп бирелгән бюджет акчасыннан максатчан файдалануны тикшерүдә тоту тотылган чыгымнарны раслый торган беренчел документларны (төп нөсхәләрен һәм оешма таныкланган күчермәләрен) тикшерү, оешмаларга барып тикшерүләр үткәрү юлы белән вәкаләтле орган тарафыннан гамәлгә ашырыла.

F:\KARAR\2015\221-1.docx